**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең Салтыган торак пунктында**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«23» октябрь, 2019 № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең Салтыган торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ :

1. 2020 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә алып барырга.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- материаллар белән паркны төзекләндерү;
- Салтыган авылы чишмәләрен төзекләндерү, чистарту һәм төзекләндерү, материаллар сатып алу белән;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү, материаллар алу белән.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Багай авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Кузнецова